БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
29 май 2020 ел

**КАРАР**
№ 243

**Татарстан Республикасы Балтач район Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яисә хәрби хәл чорларында Татарстан Республикасы Балтач район Советы депутатларының эшчәнлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. 2005 елның 21 декабрендәге 21 номерлы Татартсан Республикасы Балтач район Советы карары (2009 елның 18 декаберендәге, 2010 елның 13 нояберендәге, 2012 елның 8 февралендәге, 2014 елның 28 февралендәге, 2016 елның 23 декаберендәге үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Регламентның 26 статьясын түбәндәге эчтәлекле 5 пункты белән тулыландырырга:

«5. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы территориясендә яисә аның аерым урыннарында (Балтач муниципаль районы территориясен яки аның бер өлешен кертеп) югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш һәм хәрби хәл (алга таба - махсус режим) кертелгәндә, район Башлыгы инициативасы буенча район Советы утырышлары әлеге Регламентның 5.1 бүлегендә каралган тәртиптә дистанцион рәвештә үткәрелергә мөмкин.».

2) Регламентны түбәндәге эчтәлекле 5.1 бүлеге белән тулыландырырга:

«**5.1. бүлек.** **Район Советы утырышларын дистанцион үткәрү тәртибе**

**38.1 статья**

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы территориясендә яисә аның аерым урыннарында (Балтач муниципаль районы территориясен яки аның бер өлешен кертеп) махсус режим кертелгән чорда, Район Советы район башлыгы карары буенча видеоконференцэлемтә системаларын, мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен яки утырышта катнашучыларның онлайн-аралашу мөмкинлеген тәэмин итүче башка программаларны, техник чараларны кулланып дистанцион рәвештә (алга таба - район Советының дистанцион утырышы) үткәрелергә мөмкин.

2. Аерым очракларда (район Башлыгы булмаганда) Район Советының дистанцион утырышын үткәрү турында карар аны алмаштыручы зат тарафыннан кабул ителә.

3. Әгәр утырышта район Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыгы теркәлгән булса - Район Советының дистанцион утырышы тулы хокуклы.

4. Район Советының дистанцион утырышында катнашу мөмкинлеге булмау турында депутат Район Башлыгына алдан хәбәр итәргә тиеш.

5. Район Советының дистанцион утырышында катнашучы депутатларны теркәүне Совет аппараты оештыра.

Әгәр теркәлү нәтиҗәләре буенча район Советының дистанцион утырышы тулы хокуклы түгел дип танылса, район башлыгы карары белән дистанцион утырыш башка вакытка күчерелә, ә депутатларга район Советының дистанцион утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында хәбәр ителә.

6. Район Советының дистанцион утырышлары, кагыйдә буларак, ачык булып торалар. Кирәк булган очракта, Район Советы район Советының ябык дистанцион утырышын уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин.

7. Район Советының дистанцион утырышында Район Башлыгы яки аның вазыйфаларын башкаручы район башлыгы урынбасары рәислек итә.

8. Дистанцион утырыш үткәрү вакытында депутатлар арасыннан район советы утырышы секретаре сайлана. Район Советы утырышы секретаре, көн тәртибе һәм үткәрү тәртибе катнашучы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән кулларны күтәреп ачык тавыш бирү юлы белән раслана.

9. Депутат тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра һәм башка затка үз тавыш бирү хокукын бирергә хокуклы түгел.

10. Район Советының дистанцион утырышларында карарлар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кулларны күтәреп ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Һәр мәсьәлә буенча тавышларны санау район Советының дистанцион утырышы секретаре, шулай ук район Советы аппараты тарафыннан башкарыла. Тавыш бирү нәтиҗәләре район Советының дистанцион утырышы беркетмәсенә микъдар аңлатмасында кертелә.

Район Советының дистанцион утырышы беркетмәсен район Советы секретаре алып бара. Район Советының дистанцион утырышы беркетмәсе Регламентта каралган тәртиптә рәсмиләштерелә һәм имзалана.

11. Дистанцион утырышларда кабул ителгән карарлар әлеге Регламентта каралган тәртиптә имзалана һәм бастырып чыгару, халыкка җиткерү өчен җибәрелә.».

2. Әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин